ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 42 от «31» 01 2025 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы җирлекара
күмү урыннарында җирләү буенча
гарантияләнгән исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1.2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә 9165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2.Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 26 январендәге 33 номерлы карарын үз көчен югалтты дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары Р.М. Никифоровка йөкләргә.

Җитәкче Р.М.Гарипов

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
31 01 2025 ел , № 42 карарына
1 нче кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 4216,11 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1098,57 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3850,69 |
| Барлыгы | 9165,37 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
31 . 01 2025 ел , № 42 карарына
2 нче кушымта

2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1308,02 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3027,81 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1120,81 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3708,73 |
| Барлыгы | 9165,37 |